БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«17» 08 2020 ел № 255

**Үзәкләштерелгән җылылык белән тәэмин итү, су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны чыгару системалары өчен гарантияләүче оешманы билгеләү һәм аның эшчәнлеге зонасын билгеләү турында**

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы авыл җирлекләре территориясендә җылылык белән, су белән өзлексез тәэмин итүне һәм ташландык суларны өзлексез чыгаруны оештыру максатларында, «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны чыгару турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль законның 6, 11, 12 статьялары, «Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты турында нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Әлеге карарның 1 нче һәм 2 нче кушымталарында күрсәтелгән Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы авыл җирлекләре территориясендә үзәкләштерелгән җылылык белән тәэмин итү, су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны чыгару системалары өчен гарантияләүче оешма итеп «Торак-коммуналь хуҗалыкның Балтач күптармаклы җитештерү предприятиесе» акционер җәмгыятен билгеләргә.

2. «Торак-коммуналь хуҗалыкның Балтач күптармаклы җитештерү предприятиесе» акционер җәмгыятенә «Торак-коммуналь хуҗалыкның Балтач күптармаклы җитештерү предприятиесе» акционер җәмгыяте тарафыннан эксплуатацияләнә торган җылылык белән тәэмин итү, су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны чыгару челтәрләренә билгеләнгән тәртиптә тоташтырылган капиталь төзелеш объектлары булган абонентларга җылылык белән тәэмин итүне, су белән тәэмин итүне һәм ташландык суларны чыгаруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Балтач муниципаль районының рәсми baltasi.tatarstan.ru сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак – коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгына йөкләргә.

Җитәкче А. Ф. Хәйретдинов

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2020 елның 11.08
255 номерлы карарына
1 нче кушымта

Җылылык белән тәэмин итү буенча гарантияләүче оешма тарафыннан хезмәт күрсәтелә торган авыл җирлекләре исемлеге

| т/б | Җирлек исеме |
|---|---|
| 1. | Норма АҖ |
| 2. | Кече Лызи АҖ |
| 3. | Карадуган АҖ |
| 4. | Борбаш АҖ |
| 5. | Яңгул АҖ |
| 6. | Сосна АҖ |

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2020 елның 17.08
255 номерлы карарына
2 нче кушымта

Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны чыгару буенча гарантияләүче оешма тарафыннан хезмәт күрсәтелә торган авыл җирлекләре исемлеге

| т/б | Җирлек исеме |
|---|---|
| 1. | Норма АҖ |
| 2. | Кече Лызи АҖ |
| 3. | Карадуган АҖ |
| 4. | Борбаш АҖ |
| 5. | Яңгул АҖ |